ГЛАВА ОКТЯБРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.7, пос. Октябрьский, 422580

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 7 нче йорт, Октябржский авылы, 422580

Тел.: (84379) 31-4-27, факс: (84379) 31-4-27.

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№2 28.11.2025 ел

«Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел, №33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2026 елда Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән килешәсезме?:

- Ремонт, коймалар урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү (Октябрьский поселогы зиратлары территориясен төзекләндерү) дигән сорау буенча 2025 елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 351 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 264 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 264 кеше тавыш бирде;
- «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде
- тавыш бирүдән тыелган 0 кеше.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Октябрьский поселогында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2026 елда Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтүгә ризамы:

- Октябрьский поселогы зиратлары территориясен төзекләндерү (ремонт, коймалар урнаштыру, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү), дигән сорау буенча карарны кабул ителгән дип санарга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегенең Октябрьский поселогы гражданнары җыены нәтиҗәләрен Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Ш.Р. Азизов